# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» и Закон Республики Татарстан «О порядке представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 февраля 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 3 (I часть); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I часть); 2011, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I часть), № 12 (II часть); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I), № 94 (часть I); 2020, № 57 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2023, № 3 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 1 статьи 4 дополнить подпунктом «л» следующего содержания:
«л) отсутствия депутата без уважительных причин на всех заседаниях Государственного Совета Республики Татарстан в течение шести месяцев подряд.»;

2) пункт 1 статьи $10^{1}$ дополнить предложениями следующего содержания: «Депутат, осуществляющий свои полномочия без отрыва от основной деятельности, представляет указанные сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера в течение четырех месяцев со дня избрания депутатом, передачи ему вакантного депутатского мандата. Депутат, осуществляющий свои полномочия без отрыва от основной деятельности, в случаях, предусмотренных

частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», представляет сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера в соответствии с законодательством Российской Федерации. В случае, если в течение отчетного периода сделки, предусмотренные частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», общая сумма которых превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду, не совершались, депутат сообщает об этом в Комиссию посредством направления уведомления по форме согласно приложению 4 к настоящему Закону.»;

3) пункт 20 статьи $10^3$ изложить в следующей редакции:

«20. Обеспечение доступа к информации о представляемых депутатами сведениях о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, к информации о представлении депутатами заведомо недостоверных или неполных сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, выявленных Комиссией, осуществляется в соответствии с федеральными законами, указами Президента Российской Федерации.»;

4) дополнить приложением 4 следующего содержания:

«Приложение 4 к Закону Республики Татарстан
«О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан»

В Комиссию Государственного Совета Республики Татарстан по контролю за достоверностью сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых депутатами Государственного Совета Республики Татарстан

Уведомление

Я, депутат Государственного Совета Республики Татарстан ________________________________________________,

фамилия, имя и (при наличии) отчество

«___»______________ _______ года рождения, паспорт серия ______ №______________, ______________________________________

дата выдачи и орган, выдавший паспорт

____________________________________________________,

в соответствии с частью 4[1-2] статьи 12[1] Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и пунктом 1 статьи 10[1] Закона Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» уведомляю о том, что мной, моей (моим) супругой (супругом) и (или) несовершеннолетними детьми сделки, предусмотренные частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам» (сделки по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), цифровых финансовых активов, цифровой валюты), общая сумма которых превышает общий наш (мой и моей (моего) супруги (супруга) доход за три последних года, предшествующих отчетному периоду, в течение отчетного периода с 1 января по 31 декабря 20__ года не совершались.

Достоверность настоящих сведений подтверждаю.

«____»_____________ 20__г. ________________________________

подпись лица, представившего уведомление

________________________________________________

(фамилия, имя и (при наличии) отчество и подпись лица, уполномоченного на принятие уведомления)».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 19 июля 2017 года № 56-ЗРТ «О порядке представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 37 (часть I); 2021, № 1 (часть I); 2022, № 49 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 2:

а) в абзаце первом части 4 слова «(за исключением лиц, замещающих муниципальные должности депутатов представительных органов сельских поселений и осуществляющих свои полномочия на непостоянной основе)» заменить словами «(за исключением лиц, замещающих муниципальные должности депутатов представительных органов муниципальных образований и осуществляющих свои полномочия на непостоянной основе)»;

б) часть 4[1] изложить в следующей редакции:

«4[1]. Лицо, замещающее муниципальную должность депутата представительного органа муниципального образования и осуществляющее свои

полномочия на непостоянной основе, представляет сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера в течение четырех месяцев со дня избрания депутатом, передачи ему вакантного депутатского мандата. Лицо, замещающее муниципальную должность депутата представительного органа муниципального образования и осуществляющее свои полномочия на непостоянной основе, в случаях, предусмотренных частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», представляет сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера в соответствии с законодательством Российской Федерации. В случае, если в течение отчетного периода сделки, предусмотренные частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», общая сумма которых превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду, не совершались, лицо, замещающее муниципальную должность депутата представительного органа муниципального образования и осуществляющее свои полномочия на непостоянной основе, сообщает об этом Главе (Раису) Республики Татарстан посредством направления уведомления с использованием специализированного информационного ресурса, предусмотренного частью 2 настоящей статьи, по форме согласно приложению к настоящему Закону. Предусмотренные настоящей частью уведомление, а также сведения (в случае совершения в течение отчетного периода сделок, предусмотренных частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам») представляются в срок, который установлен для представления сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера государственными гражданскими служащими Республики Татарстан.

Обеспечение доступа к информации о представляемых лицами, замещающими муниципальные должности депутата представительного органа муниципального образования, сведениях о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, к информации о представлении такими лицами заведомо недостоверных или неполных сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера осуществляется в соответствии с федеральными законами, указами Президента Российской Федерации.

Копия уведомления на бумажном носителе, подписанная лицом, замещающим муниципальную должность депутата представительного органа муниципального образования и осуществляющим свои полномочия на непостоянной основе, направляется должностному лицу, ответственному за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений в соответствующем муниципальном районе (городском округе), и подлежит хранению в соответствии с законодательством.»;

2) приложение изложить в следующей редакции:

«Приложение к Закону Республики Татарстан «О порядке представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту»

Главе (Раису) Республики Татарстан

______________________________

Уведомление

Я, депутат ____________________________________________________________
наименование представительного органа муниципального образования

____________________________________________________ муниципального района
наименование муниципального района (указывается в случае, если уведомление представляется депутатом сельского или городского поселения)

___________________________________________________________________________,
фамилия, имя и (при наличии) отчество

«___»_______________ ________ года рождения, паспорт серия ______ №______________, ________________________________________________________
дата выдачи и орган, выдавший паспорт

___________________________________________________________________________,

в соответствии с частью $4^2$ статьи $12^1$ Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и частью $4^1$ статьи 2 Закона Республики Татарстан от 19 июля 2017 года № 56-ЗРТ «О порядке представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту» уведомляю Вас о том, что мной, моей (моим) супругой (супругом) и (или) несовершеннолетними детьми сделки, предусмотренные частью 1 статьи 3 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам» (сделки по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), цифровых финансовых активов, цифровой валюты), общая сумма которых превышает общий наш (мой и моей (моего) супруги (супруга) доход за три последних года, предшествующих отчетному периоду, в течение отчетного периода с 1 января по 31 декабря 20__ года не совершались.

Достоверность настоящих сведений подтверждаю.

«____»_____________ 20__г. ________________________________________

подпись лица, представившего уведомление

_____________________________________________________________________

(фамилия, имя и (при наличии) отчество и подпись лица, уполномоченного на принятие уведомления)».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 марта 2023 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
24 февраля 2023 года
№ 7-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында»Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «л» пунктчасы өстәргә:
«л) депутат рәттән алты ай дәвамында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының барлык утырышларында нигезсез сәбәпләр буенча булмаганда.»;

2) $10^{1}$ статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Үз вәкаләтләрен төп эшчәнлегеннән аерылмыйча гамәлгә ашыручы депутат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы әлеге белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылган көннән алып дүрт ай дәвамында тапшыра. Үз вәкаләтләрен төп эшчәнлегеннән аерылмыйча гамәлгә ашыручы депутат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы

1 өлешендә каралган очракларда керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшыра. Хисап чоры дәвамында, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган, гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән арткан алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, депутат бу хакта әлеге Законга 4 нче кушымтада каралган форма буенча хәбәрнамә җибәрү юлы белән Комиссиягә хәбәр итә.»;

3) $10^3$ статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләр хакындагы мәгълүматтан, депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне тапшыру хакындагы Комиссия тарафыннан ачыкланган мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә

Хәбәрнамә

Мин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты___________________
________________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)
_______ елның «___»___________ туган, паспорт сериясе ______ №____________,
________________________________________________________________________,
паспорт бирелгән дата һәм аны биргән орган

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $4^{1-2}$ өлеше һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы 1 пункты нигезендә түбәндәгеләрне хәбәр итәм: 20 ___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чоры дәвамында минем тарафтан, хатыным (ирем) һәм (яисә) балигъ

булмаган балаларым тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган гомуми суммасы безнең (минем һәм хатынымның (иремнең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда алган гомуми керемнән артык булган алыш-бирешләр (җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта алу буенча алыш-бирешләр) ясалмады.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«____»_____________ 20__ ел ______________________________

хәбәрнамә тапшырган зат имзасы

______________________________________________________________

(хәбәрнамәне кабул итәргә вәкаләт бирелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм имзасы)».

**2 статья**

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 4 өлешнең беренче абзацында «(авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатлары муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы затлардан тыш)» сүзләрен «(муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы затлардан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

б) $4^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$4^1$. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылган көннән алып дүрт ай эчендә тапшыра. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору

турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшыра. Хисап чоры дәвамында, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган, гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән арткан алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат бу хакта, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып, әлеге Законга кушымтада каралган форма буенча хәбәрнамә җибәрү юлы белән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә. Әлеге өлештә каралган хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр ясалган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән срокта тапшырыла.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында тапшырыла торган белешмәләр турындагы мәгълүматтан, мондый затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне тапшыру хакындагы мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Хәбәрнамәнең муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазь күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш була.»;

2) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Татарстан Республикасы Рәисе

____________________________

Хәбәрнамә

Мин, ___________________________________________ муниципаль районы
муниципаль район исеме

__________________________________________________________________ депутаты
муниципаль берәмлек вәкиллекле органы исеме (хәбәрнамә авыл яисә шәһәр җирлеге депутаты тарафыннан тапшырылса гына күрсәтелә)

__________________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)

_______ елның «___»___________ туган, паспорт сериясе ______ №____________,

_________________________________________________________________________,
паспорт бирелгән дата һәм аны биргән орган

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^{1}$ статьясындагы $4^{2}$ өлеше, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^{1}$ өлеше нигезендә Сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итәм: 20 ___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чоры дәвамында минем тарафтан, хатыным (ирем) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларым тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган гомуми суммасы безнең (минем һәм хатынымның (иремнең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда алган гомуми керемнән артык булган алыш-бирешләр (җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта алу буенча алыш-бирешләр) ясалмады.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«____»______________ 20__ ел ______________________________
хәбәрнамә тапшырган зат имзасы

__________________________________________________________________________
(хәбәрнамәне кабул итеп алырга вәкаләт бирелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм имзасы)».

**3 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 24 февраль
№ 7-ТРЗ